**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-02-22, факс (85552) 3-13-44, E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru , www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

20.09.2018г. — ПР-235

**Мәгариф оешмаларына инвалидлар өчен тиешле шартлар тудыру, шулай ук аларга кирәкле ярдәм күрсәтү турында**

1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль законы «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында», 2014 елның 1 декабрендәге 419-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру максатларында «Инвалидлар хокуклары турындагы Конвенцияне ратификацияләүгә бәйле рәвештә инвалидларны социаль яклау мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" карар бирәм:

1. Белем бирү оешмаларында инвалидлар өчен шартлар тудыру , шулай ук аларга кирәкле ярдәм күрсәтү тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының МКУ " Мәгариф идарәсе» әлеге карарны мәгариф идарәсе сайтында урнаштырырга һәм Актаныш муниципаль районының мәгариф оешмалары җитәкчеләренә җиткерергә

3.Карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында һәм ТР хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының МКУ «Мәгариф идарәсе» җитәкчесенең тәрбия эшләре буенча урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы — А.И. Тимиров